ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«16» апрель 2021 ел № 283

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 18 мартындагы 181 номерлы "Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы Нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында (04.09.2020 №687;13.11.2020 №897; 19.02.2021 №94 үзгәрешләр белән)**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 18 мартындагы 181 номерлы «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (04.09.2020 №687;13.11.2020 №897; 19.02.2021 №94 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен кайтаруга юнәлдерелгән җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча гражданнарга субсидияләр бирү комиссиясе составы» исемле 2 нче кушымтаны расларга һәм яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы Г.Х. Галимуллинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Мөхәрәмов

*Арча муниципаль районы*
*башкарма комитетының*
*“ 16 " апрель 2021 ел, № 283*
*карарына кушымта*

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен кайтаруга юнәлдерелгән җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча гражданнарга субсидияләр бирү комиссиясе составы

1. Комиссия рәисе-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе-Мөхәрәмов Рәсүл Ринатович;
2. Комиссия рәисе урынбасары-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге җитәкчесе-Галимуллина Гүзәл Харисовна;
3. Комиссия секретаре - Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге баш белгече Гайнетдинова Гөлнара Рәшитовна

Комиссия әгъзалары:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы-Гатиятов Ренат Мансурович (килешү буенча);
2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе – Галимова Светлана Петровна (килешү буенча);
3. Татарстан Республикасы Арча район Советының юридик мәсьәләләр буенча бүлек башлыгы-Сәгыйтова Ләйсән Гарәфетдиновна (килешү буенча);
4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе-Сафиуллина Надия Равиловна (килешү буенча).